ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2024 с.Старое Дрожжаное № 289

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2020 N 1245, от 26.07.2021 N 645, от 30.10.2021 N 1030, от 19.02.2022 N 141, от 15.06.2022 N 566, от 22.09.2022 N 1027, от 24.05.2024 № 361карарлары редакциясендә) карарының гамәлдә булуын 2024 елның 1 июленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән җитди хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 10 декабрендәге 1192 номерлы карарын (Татарстан Республикасы Чүпрәле

муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 11 февралендәге 77 номерлы, 2013 елның 24 маендагы 412 номерлы, 2013 елның 23 июлендәге 574 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Р. Измайлов